# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Тулбай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**25 ноябрь, 2024 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде, 25.11.2024 елда узган һәм түбәндәге сорау каралган: «Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Тулбай торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1700 сум күләмендә үзара салым кертергә ризамы?, 1 төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1.Тулбай торак пунктында Сабантуй уздырыла торган территорияне төзекләндерү (материаллар сатып алу, эскәмияләр ясау, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);

2.Тулбай торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (карт агачларны кисү, эш өчен килешү буенча түләү) ;

3. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау – Тулбай торак пунктында артезиан скважиналары өчен насос сатып алу;

4.Тулбай торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (асфальт валчыклары сатып алу, ташу, салу, грейдирлау, килешү буенча эш өчен түләү)».

Гражданнар җыелышы нәтиҗәләре турындагы протокол нигезендә: тавыш бирергә хокуклы җыелышта катнашучылар исемлегендә гражданнар җыелышында 205 катнашучы бар, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыелышында катнашучылар саны 125 кеше.